КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 25 июль г.Казань № 714

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары функцияләре кодификаторын раслау турында» 2006 ел, 2 май, 220 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 12 февраль, 38 нче; 2007 ел, 13 июль, 297 нче; 2009 ел, 23 март, 161 нче; 2009 ел, 15 июнь, 386 нчы; 2010 ел, 22 февраль, 92 нче; 2010 ел, 9 апрель, 253 нче; 2011 ел, 6 июнь, 452 нче; 2011 ел, 27 июнь, 515 нче; 2011 ел, 8 сентябрь, 750 нче; 2012 ел, 9 февраль, 93 нче; 2012 ел, 29 март, 250 нче; 2012 ел, 19 июнь, 524 нче; 2012 ел, 24 декабрь, 1139 нчы; 2013 ел, 22 февраль, 128 нче; 2013 ел, 11 декабрь, 974 нче; 2014 ел, 23 гыйнвар, 30 нчы; 2014 ел, 30 август, 630 нчы; 2014 ел, 12 сентябрь, 659 нчы; 2014 ел, 30 октябрь, 823 нче; 2014 ел, 24 ноябрь, 902 нче; 2014 ел, 3 декабрь, 940 нчы; 2015 ел, 2 февраль, 49 нчы; 2016 ел, 15 апрель, 227 нче, 2016 ел, 20 август, 578 нче; 2017 ел, 3 февраль, 58 нче; 2017 ел, 16 март, 148 нче; 2017 ел, 19 июль, 508 нче; 2017 ел, 30 ноябрь, 930 нчы; 2017 ел, 15 декабрь, 999 нчы; 2017 ел, 29 декабрь, 1118 нче; 2018 ел, 12 июль, 565 нче; 2018 ел, 24 июль, 586 нчы; 2018 ел, 8 август, 643 нче; 2019 ел, 16 март, 185 нче; 2019 ел, 15 июнь, 493 нче; 2019 ел, 24 июнь, 509 нчы; 2019 ел, 19 июль, 605 нче; 2019 ел, 11 сентябрь, 814 нче; 2020 ел, 28 апрель, 344 нче; 2020 ел, 26 июнь, 531 нче; 2020 ел, 22 декабрь, 1177 нче; 2021 ел, 12 октябрь, 970 нче; 2021 ел, 2 ноябрь, 1039 нчы; 2021 ел, 8 декабрь, 1198 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары функцияләре кодификаторына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«03.02.05» юлының 8 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техника техник торышы һәм аларны эксплуатацияләү өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге)»;

«03.02.05» юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | «03.02.06 | Аттракционнарның техник торышы һәм аларны эксплуатацияләү өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) | ТР Дәүләт техника күзәтчелеге идарәсе». | | | |

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре техник торышына күзәтчелек итү идарәсе турында» 2011 ел, 26 декабрь, 1064 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 10 март, 204 нче; 2012 ел, 28 май, 425 нче; 2012 ел, 25 август, 737 нче; 2013 ел, 14 ноябрь, 874 нче; 2014 ел, 7 июнь, 389 нчы; 2016 ел, 13 август, 557 нче; 2016 ел, 30 декабрь, 1050 нче; 2017 ел, 27 ноябрь, 912 нче; 2018 ел, 12 май, 352 нче; 2018 ел, 29 октябрь, 956 нчы; 2019 ел, 15 гыйнвар, 2 нче; 2019 ел, 19 июль, 605 нче; 2020 ел, 28 апрель, 344 нче; 2020 ел, 15 сентябрь, 833 нче; 2020 ел, 9 ноябрь, 1001 нче; 2021 ел, 26 февраль, 102 нче; 2021 ел, 21 июль, 623 нче; 2021 ел, 27 ноябрь, 1139 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктта:

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«аппаратта вазыйфаи окладлар буенча 438,973 мең сум күләмендәге айлык хезмәт өчен түләү фонды белән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган 19 берәмлек итеп;»;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«территориаль бүлекләрдә вазыйфаи окладлар буенча 1 021,602 мең сум күләмендәге айлык хезмәт өчен түләү фонды белән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган 57 берәмлек итеп.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре техник торышына күзәтчелек итү идарәсе турындагы нигезләмәдә:

1.1 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Татарстан Республикасының Үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре техник торышына күзәтчелек итү идарәсе (алга таба – Татарстан Республикасы Дәүләт техника күзәтчелеге идарәсе) – үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре техник торышы һәм аларны эксплуатацияләү өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге), аттракционнарның техник торышы һәм аларны эксплуатацияләү өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге), махсус юл транспортын техник эксплуатацияләү кагыйдәләренең һәм махсус юл транспортыннан файдалану кагыйдәләренең үтәлешенә федераль дәүләт контроле (күзәтчелеге) буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы махсус компетенциядәге Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы.»;

2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Бурычлар

2.1. Татарстан Республикасының Үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре техник торышына күзәтчелек итү идарәсенең төп бурычлары:

үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре техник торышы һәм аларны эксплуатацияләү өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге);

аттракционнарның техник торышы һәм аларны эксплуатацияләү өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге);

махсус юл транспортын техник эксплуатацияләү кагыйдәләре һәм махсус юл транспортыннан файдалану кагыйдәләре үтәлешенә федераль дәүләт контроле (күзәтчелеге).»;

3.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Татарстан Республикасының Үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре техник торышына күзәтчелек итү идарәсе үзенә йөкләнгән бурычлар нигезендә түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашыра:

үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре техник торышы һәм аларны эксплуатацияләү өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) (03.02.05*);

аттракционнарның техник торышы һәм аларны эксплуатацияләү өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) (03.02.06*);

махсус юл транспортын техник эксплуатацияләү кагыйдәләре һәм махсус юл транспортыннан файдалану кагыйдәләре үтәлешенә федераль дәүләт контроле (күзәтчелеге) (03.03.07*);»;

4.1 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре техник торышы һәм аларны эксплуатацияләү өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге);»;

дүртенче – җиденче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«үзйөрешле машиналарны һәм техниканың башка төрләрен дәүләт теркәвенә алу турында таныклык һәм дәүләт теркәвенә алу билгесен биреп, үзйөрешле машиналарны һәм техниканың башка төрләрен дәүләт теркәвенә алу;

үзйөрешле машиналарга һәм техниканың башка төрләренә техник тикшерү үткәрү;

үзйөрешле машиналар белән идарә итү хокукына имтиханнар кабул итү һәм үзйөрешле машиналар белән идарә итү хокукын раслый торган тракторчы-машинист (тракторчы) таныклыгын яки тиешле категорияләрдәге үзйөрешле машиналар белән идарә итү хокукына вакытлыча таныклык бирү;

белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларга тракторчылар, машинистлар һәм үзйөрешле машиналар йөртүчеләр әзерләү өчен җиһазларның һәм белем бирү процессы җиһазландырылышының таләпләргә туры килүе турында таныклык бирү;»;

егерме өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«махсус юл транспортын техник эксплуатацияләү кагыйдәләре һәм махсус юл транспортыннан файдалану кагыйдәләре үтәлешенә федераль дәүләт контроле (күзәтчелеге);»;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре паспортларын һәм аларның дубликатларын, шулай ук Евразия икътисадый берлеге хокукын тәшкил итә торган актлар нигезендә әлеге гамәлдәге паспортлар бланкларын бирү;

үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре техник торышы һәм аларны эксплуатацияләү өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибе нигезендә үзйөрешле машиналарны һәм техниканың башка төрләрен эксплуатацияләүне тыю;

аттракционнарның техник торышы һәм аларны эксплуатацияләү өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге).».

3. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

бу карарның 1 пункты, 2 пунктындагы сигезенче – егерме өченче, утыз җиденче абзацлары 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә;

бу карарның 2 пунктындагы егерме дүртенче – утыз алтынчы абзацларының гамәлдә булуы 2022 елның 3 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин